ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 4 июлендәге 782 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турында төзелгән килешүләргә түбәндәге өстәмә килешүләрне расларга:

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы килешүгә 2018 елның 29 декабрендәге 2 номерлы өстәмә килешү, әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы килешүгә 2018 елның 29 декабрендәге 2 номерлы өстәмә килешү, әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә;

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүгә 2018 елның 29 декабрендәге 2 номерлы өстәмә килешү, әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 19 февраль
№ 2-ТРЗ

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы килешүгә 2 номерлы өстәмә килешү**

Мәскәү ш. 2018 елның 29 декабре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В.Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында«Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 4 июлендәге 782 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Яклар Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы килешүгә (алга таба – Килешү) 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүнең (алга таба - 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешү) 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертү турында килештеләр:

«5. Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычларны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы өлешендә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта Заемщик йөкләмәләрне үти башлау срогына Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән төп ставканың 1/300 күләмендә пени түли, бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменнән йөкләмәләр үтәлмәгән һәр көн өчен.

Бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы белән билгеләнгән түләү көне килеп җиткәннән соң 14 эш көне узганнан соң да Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурыч һәм (яки) өлешләп түләү процентлары түләнмәгән очракта, төп бурыч буенча капланмаган реструктуризацияләнгән бурыч һәм кредит буенча процентлар, шулай ук график буенча конкрет датага караган өлешләп түләү процентлары Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы капланырга тиешләр. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пенилар да түләнергә тиеш.

Заемщик 2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең (алга таба – Кагыйдәләр) 11 пунктындагы «з» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, һәм 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «е» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, Заемщик Кредитор күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәр иткән вакыттан алып 60 көн эчендә капланмаган төп бурыч һәм кредитлар буенча процентлар буенча реструктуризацияләнгән бурычны, шулай ук Заемщик тиешле чорда фактта түләгән өлешләп түләү процентлары суммаларын чигереп, өлешләп түләү процентларын вакытыннан алда берьюлы каплый.

Заемщик хисап елы нәтиҗәләре буенча Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б» - «г» пунктчалары һәм әлеге 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «б»-«в» пунктчалары нигезләмәләрен үтәмәгәндә, Заемщик агымдагы финанс елында бурычларны түләү графигы нигезендә бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм өлешләп түләгән өчен процентларны каплый, шулай ук Кредиторның күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәре нигезендә Россия Федерациясе субъекты бюджет кытлыгының иң чик күрсәткечләреннән арткан күләмдәге һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләмендәге бурычын, шул исәптән Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары буенча Кагыйдәләр һәм 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешү белән билгеләнгән йөкләмәләрен вакытыннан алда каплый, ләкин агымдагы елның 1 июленә кадәр реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменең 20 процентыннан да артыгын түгел (бурычларны үтәмәү гадәттән тыш хәлләр яки Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) алмашыну аркасында килеп чыккан очраклардан тыш).

Заемщикның Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «а», «д» - «ж», «и» һәм «к» пунктчаларын, шулай ук 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «а», «г», «д», «ж» һәм «з» пунктчаларын үтәмәве Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чараларын куллануга китерә.

Заемщик Кредиторның Өстәмә Килешүнең әлеге пунктындагы икенче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән таләпләрен үтәмәгәндә Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган чаралар кулланыла.

2. Килешүнең аңа каршы килми торган һәм әлеге Өстәмә килешүдә кагылмаган калган шартлары үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үзләренең йөкләмәләрен раслыйлар.

3. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Өстәмә килешү һәр як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 3 биттә төзелде.

**Юридик адреслар**

**Кредитор:** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы,
Ильинка ур., 9, Мәскәү ш., 109097.

**Заемщик:** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты,
Ирек мәйданы, 1, Казан ш., 420060.

**Якларның имзалары**

| | |
|---|---|
| **Кредитордан:** | **Заемщиктан:** |
| Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары | Татарстан Республикасы Премьер-министры |
| __________________Л.В. Горнин | _________________А.В. Песошин |
| **М.У.** | **М.У.** |

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы килешүгә 2 номерлы өстәмә килешү**

Мәскәү ш. 2018 елның 29 декабре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В.Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 4 июлендәге 782 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Яклар Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы килешүгә (алга таба – Килешү) 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүнең (алга таба - 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешү) 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертү турында килештеләр:

«5. Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычларны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы өлешендә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта Заемщик йөкләмәләрне үти башлау срогына Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән төп ставканың 1/300 күләмендә пени түли, бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменнән йөкләмәләр үтәлмәгән һәр көн өчен.

Бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы белән билгеләнгән түләү көне килеп җиткәннән соң 14 эш көне узганнан соң да Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурыч һәм (яки) өлешләп түләү процентлары түләнмәгән очракта, төп бурыч буенча капланмаган реструктуризацияләнгән бурыч һәм кредит буенча процентлар, шулай ук график буенча конкрет датага караган өлешләп түләү процентлары Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы капланырга тиешләр. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пенилар да түләнергә тиеш.

Заемщик 2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең (алга таба – Кагыйдәләр) 11 пунктындагы «з» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, һәм 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «е» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, Заемщик Кредитор күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәр иткән вакыттан алып 60 көн эчендә капланмаган төп бурыч һәм кредитлар буенча процентлар буенча реструктуризацияләнгән бурычны, шулай ук Заемщик тиешле чорда фактта түләгән өлешләп түләү процентлары суммаларын чигереп, өлешләп түләү процентларын вакытыннан алда берьюлы каплый.

Заемщик хисап елы нәтиҗәләре буенча Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б» - «г» пунктчалары һәм әлеге 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «б»-«в» пунктчалары нигезләмәләрен үтәмәгәндә, Заемщик агымдагы финанс елында бурычларны түләү графигы нигезендә бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм өлешләп түләгән өчен процентларны каплый, шулай ук Кредиторның күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәре нигезендә Россия Федерациясе субъекты бюджет кытлыгының иң чик күрсәткечләреннән арткан күләмдәге һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләмендәге бурычын, шул исәптән Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары буенча Кагыйдәләр һәм 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешү белән билгеләнгән йөкләмәләрен вакытыннан алда каплый, ләкин агымдагы елның 1 июленә кадәр реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменең 20 процентыннан да артыгын түгел (бурычларны үтәмәү гадәттән тыш хәлләр яки Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) алмашыну аркасында килеп чыккан очраклардан тыш).

Заемщикның Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «а», «д» - «ж», «и» һәм «к» пунктчаларын, шулай ук 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «а», «г», «д», «ж» һәм «з» пунктчаларын үтәмәве Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чараларын куллануга китерә.

Заемщик Кредиторның Өстәмә Килешүнең әлеге пунктындагы икенче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән таләпләрен үтәмәгәндә Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган чаралар кулланыла.

2. Килешүнең аңа каршы килми торган һәм әлеге Өстәмә килешүдә кагылмаган калган шартлары үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үзләренең йөкләмәләрен раслыйлар.

3. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Өстәмә килешү һәр як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 3 биттә төзелде.

**Юридик адреслар**

**Кредитор:** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы,
Ильинка ур., 9, Мәскәү ш., 109097.

**Заемщик:** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты,
Ирек мәйданы, 1, Казан ш., 420060.

**Якларның имзалары**

| | |
|---|---|
| **Кредитордан:** | **Заемщиктан:** |
| Россия Федерациясе<br>Финанс министрының<br>беренче урынбасары | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| ________________Л.В. Горнин | ________________А.В. Песошин |
| **М.У.** | **М.У.** |

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүгә 2 номерлы өстәмә килешү**

Мәскәү ш. 2018 елның 29 декабре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В.Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 4 июлендәге 782 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Яклар Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүгә (алга таба – Килешү) 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүнең (алга таба - 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешү) 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертү турында килештеләр:

«5. Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычларны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы өлешендә 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта Заемщик йөкләмәләрне үти башлау срогына Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән төп ставканың 1/300 күләмендә пени түли, бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменнән йөкләмәләр үтәлмәгән һәр көн өчен.

Бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы белән билгеләнгән түләү көне килеп

Бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм (яки) өлешләп түләү процентларын түләү графигы белән билгеләнгән түләү көне килеп җиткәннән соң 14 эш көне узганнан соң да Заемщик тарафыннан бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурыч һәм (яки) өлешләп түләү процентлары түләнмәгән очракта, төп бурыч буенча капланмаган реструктуризацияләнгән бурыч һәм кредит буенча процентлар, шулай ук график буенча конкрет датага караган өлешләп түләү процентлары Заемщик тарафыннан вакытыннан алда берьюлы капланырга тиешләр. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пенилар да түләнергә тиеш.

Заемщик 2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең (алга таба – Кагыйдәләр) 11 пунктындагы «з» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, һәм 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «е» пунктчасы нигезләмәләрен бозган очракта, Заемщик Кредитор күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәр иткән вакыттан алып 60 көн эчендә капланмаган төп бурыч һәм кредитлар буенча процентлар буенча реструктуризацияләнгән бурычны, шулай ук Заемщик тиешле чорда фактта түләгән өлешләп түләү процентлары суммаларын чигереп, өлешләп түләү процентларын вакытыннан алда берьюлы каплый.

Заемщик хисап елы нәтиҗәләре буенча Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «б» - «г» пунктчалары һәм әлеге 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «б»-«в» пунктчалары нигезләмәләрен үтәмәгәндә, Заемщик агымдагы финанс елында бурычларны түләү графигы нигезендә бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны һәм өлешләп түләгән өчен процентларны каплый, шулай ук Кредиторның күрсәтелгән шартларның үтәлмәве турында хәбәре нигезендә Россия Федерациясе субъекты бюджет кытлыгының иң чик күрсәткечләреннән арткан күләмдәге һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычы күләмендәге бурычын, шул исәптән Россия Федерациясе субъектының дәүләт кыйммәтле кәгазьләре һәм Россия Федерациясе субъектының кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан алган кредитлары буенча Кагыйдәләр һәм 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә килешү белән билгеләнгән йөкләмәләрен вакытыннан алда каплый, ләкин агымдагы елның 1 июленә кадәр реструктуризацияләнгән бурычның гомуми күләменең 20 процентыннан да артыгын түгел (бурычларны үтәмәү гадәттән тыш хәлләр яки Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте югары башкарма органы җитәкчесе) алмашыну аркасында килеп чыккан очраклардан тыш).

Заемщикның Кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «а», «д» - «ж», «и» һәм «к» пунктчаларын, шулай ук 2017 елның 25 декабрендәге 1 номерлы Өстәмә Килешүнең 4 пунктындагы «а», «г», «д», «ж» һәм «з» пунктчаларын үтәмәве Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар җаваплылык чараларын куллануга китерә.

Заемщик Кредиторның Өстәмә Килешүнең әлеге пунктындагы икенче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән таләпләрен үтәмәгәндә Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган чаралар кулланыла.

2. Килешүнең аңа каршы килми торган һәм әлеге Өстәмә килешүдә кагылмаган калган шартлары үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үзләренең йөкләмәләрен раслыйлар.

3. Әлеге Өстәмә килешү Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора һәм Яклар тарафыннан имзаланган көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Өстәмә килешү һәр як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 3 биттә төзелде.

**Юридик адреслар**

**Кредитор:** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы,
Ильинка ур., 9, Мәскәү ш., 109097.

**Заемщик:** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты,
Ирек мәйданы, 1, Казан ш., 420060.

**Якларның имзалары**

| **Кредитордан:** | **Заемщиктан:** |
|---|---|
| Россия Федерациясе<br>Финанс министрының<br>беренче урынбасары | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| __________________Л.В. Горнин | _________________А.В. Песошин |
| **М.У.** | **М.У.** |